**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**12.12.2023 ел** **№ 1874**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында» 2023 елның 2 июнендәге 716 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында» 2023 елның 2 июнендәге 716 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында нигезләмә» нең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Оештыручы:

- бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашыру өчен гомуми файдаланудагы җирләрдә конкрет урынны (урыннарны) билгели;

- бәйрәм чараларын уздыруда катнашучы хуҗалык субъектлары өчен бәйрәм сәүдәсен оештыру таләпләренең үтәлешен контрольдә тота;

- сәүдә хокукына рөхсәт бирүдән хуҗалык итүче субъектка баш тарта, әгәр:

а) эшкуарлык эшчәнлеге дәүләт теркәвеннән башка гамәлгә ашырылса, шулай ук салым органында исәпкә куелмыйча эшчәнлек алып барылса,

б) һөнәри керемгә салым түләүче юридик зат, индивидуаль эшкуар, физик зат эшчәнлегенең төре бәйрәм сәүдәсендә объектны урнаштыруның күздә тотыла торган урыны билгеләнүенә туры килми,

г) моңа кадәр мондый чаралар уздырганда хуҗалык итүче субъект гамәлдәге нигезләмәне бозуга юл куйган булган,

д) продукция ассортименты санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан сатучыларга карата куелган таләпләргә туры килмәгән очракта, һәм мондый орган тарафыннан Оештыручы адресына җибәрелгән мондый

туры килмәү турында язмача хәбәр булган очракта.»;

1.2. Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымтада «янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен» сүзләрен «янгынга каршы режим кагыйдәләрен» нә алмаштырырга;

1.3. Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымтада «янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән» сүзләрен «янгынга каршы режим кагыйдәләре белән» гә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин